Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

12 май 2021 ел №53

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2013 елның 19 апрелендәге 295 номерлы «Социаль наем һәм дәүләт торак программалары буенча гражданнарга торак урыннары бирү һәм исәпкә куелганда торак мәйданы нормалары турында» гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 14, 50 статьялары, Әлмәт муниципаль районы Уставы нигезендә һәм дәүләт торак программаларын гамәлгә ашыру максатларында

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2013 елның 19 апрелендәге 295 номерлы «Социаль наем һәм дәүләт торак программалары буенча гражданнарга торак урыннары бирү һәм исәпкә куелганда торак мәйданы нормалары турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннар белән тәэмин ителешнең ирешелгән дәрәҗәсеннән чыгып, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында бер гражданга торак урынның гомуми мәйданы нормасын бер кешегә 18 квадрат метр күләмендә билгеләргә. Торак урынның гомуми мәйданын бирү нормасын арттыру Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда рөхсәт ителә.».

2. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Хамадьяров Р.Р.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов